**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«21» июнь 2016 ел Күзкәй авылы № 26

Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты
җитәкчесенең административ регламентларны
раслау турында карарына үзгәрешләр кертү турында

«Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 30 сентябрендәге 41 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Капиталь төзелеш объектына адрес бирү (үзгәртү, юкка чыгару) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.14 пунктын 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Гәрәев